  

23 апрель көнне Г.Тукайның тууына 135 еллыгына багышланган “Тукай әкиятләре илендә” дип исемләнгән әдәби бәйрәм булып узды. Бәйрәмдә балалар шагыйрьнең шигырьләрен укыдылар, аның сүзләренә язылган җырларын башкардылар. “Туган авыл” биюе бәйрәмебезне тагын да тулыландырды. Чарабызга чакырылган Арча станциясендә урнашкан күпфункцияле үзәк китапханәчеләренең чыгышы балаларга бик ошады. Бәйрәм күңелле һәм эчтәлекле булды.